**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәр Советы**

Азнакай шәһәре № 164-41 «12» март 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азакай шәһәре Советының 2017 елның 29 сентябрендәге 63-18 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәренең шәһәр төзелеше проектлау нормативлары турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәренең шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү хакында (13.12.2018 №120-29, 23.05.2019 №137-33, 20.08.2019 №144-35, 22.10.2019 №151-36, 12.12.2019 №156-38 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын үтәү йөзеннән, 2012 елның 10 июлендәге 117-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында Техник регламент» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азакай шәһәре Советының 2017 елның 29 сентябрендәге 63-18 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәренең шәһәр төзелеше проектлау нормативлары турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәренең шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларына (13.12.2018 №120-29, 23.05.2019 №137-33, 20.08.2019 №144-35, 22.10.2019 №151-36, 12.12.2019 №156-38 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.2 бүлектә:

а) 5.2.129 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ачык һәм ябык типтагы автостоянкалардан күрше объектларга кадәр ераклыкны Шәһәр төзелешенең СП 42.13330.2016 СНиП 2.07.01-89 таләпләренә

туры китереп кабул итәргә кирәк. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документларының СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 исәпкә алып башкарылырга тиеш.»;

б) 5.2.176 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Автомобильләргә хезмәт күрсәтү объектларыннан күрше объектларга кадәр ераклыкны Шәһәр төзелешенең СП 42.13330.2016, СНиП 2.07.01.-89 таләпләренә туры китереп кабул итәргә кирәк. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документларының СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 исәпкә алып башкарылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http: //pravo. tatarstan. ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http: //aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай муниципаль районы советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Рәис М.З. Шәйдуллин